СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**28.10.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 27**

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 3 июнендәге 76 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 8 өлешенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы үз эшчәнлегендәге оештыру һәм процедура мәсьәләләрен җайга салу максатларында **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 3 июнендәге 76 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 2 өлешендә «, Зеленодольск районы сайлау комиссиясе (алга таба - Сайлау комиссиясе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 13 статьяның 1 өлешендә «, Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 16 статьяның 3 өлешендә «, Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 34 статьяның 3 өлешендә «, Президиумны оештыру» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru/) сайтында игълан итәргә (бастырырга).

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**